**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5192**
**03.10.2022**

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына ярдәм күрсәтү чаралары турында

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына ярдәм күрсәтү максатында, «Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге Федераль законның 8 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2021 елның 9 декабрендәге 10/3 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның Яр Чаллы шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балалар өчен түбәндәге ярдәм күрсәтү чараларын билгеләргә:

1) муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларны 2022 елның 1 октябреннән түләүсез кайнар ризык белән тукландырырга:

1-4 сыйныф укучылары өчен – бер көнгә бер укучыга туклану бәясе 100,15 сум;

5-11 сыйныф укучылары өчен – бер көнгә бер укучыга туклану бәясе 107,64 сум;

2) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә учреждениеләргә (балалар бакчаларына) йөрүче балаларының ата-аналарын (законлы вәкилләрен) балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән 2022 елның 3 октябреннән азат итәргә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктының 1-2 пунктчаларында күрсәтелгән чыгымнарны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2022 ел бюджетында «Гаиләне һәм балачакны саклау» 10.04 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына – 1 957 858,72 сум (бер миллион тугыз йөз илле җиде мең сигез йөз илле сигез сум 72 тиен), «Мәктәпкәчә белем бирү» 07.01 бүлеге

(бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына – 2 541 180,00 сум (ике миллион биш йөз кырык бер мең йөз сиксән сум 00 тиен) күләмендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән балалар укый торган муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә:

1) түләүсез кайнар ризык белән тукландыру турында ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) гаризалар кабул итү эшен оештырырга;

2) укучыларны тукландыруны оештырырга;

3) кирәк булганда, муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларга, махсус медицина күрсәткечләре буенча өйдә укучыларга туклану продуктлары җыелмасын бирүне оештырырга;

4) әлеге карарда каралган ярдәм чараларын күрсәтү максатында, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балалары санын даими мониторинглауны алып барырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән балалар йөри торган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә:

1) баланы карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү турында ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) гаризалар кабул итү эшен оештырырга;

2) әлеге пунктта күрсәтелгән балаларны карауны һәм тәрбияләүне оештырырга;

3) әлеге карарда каралган ярдәм чараларын күрсәтү максатында, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның мәктәпкәчә төп белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль мәктәпкәчә учреждениеләргә (балалар бакчаларына) йөрүче балалары санын даими мониторинглауны алып барырга.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябрендә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов